**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алан-Бексер, ул. Центральная, д.19

422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт

Тел./факс: + 7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**05 мая 2018 ел** **№ 127**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирлектә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ булган аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзү һәм карап тоту, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2017 ел, 28 ноябрь, 105 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында" 05.04.2013 ел, № 44-ФЗ Федераль законы, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирлектә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ булган аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзү һәм карап тоту, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2017 ел 28 ноябрь, 105 нчы карарының 2 кушымтасы – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты арасындагы Килешүгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пункты 1.2.2 пунктчасының 6, 9, 11 абзацларында «муниципаль заказ» сүзен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алу»сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина